ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш), «400 мең сумнан» сүзләрен «торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрына Татарстан Республикасы буенча уртача базар бәясенең Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган күрсәткеченнән һәм ике кешедән гыйбарәт яшь гаилә (яшь парлар яисә бер яшь әти яки әни һәм бер бала) өчен 42 квадрат метр булган, яшь парлардан кала тагын бер яисә аннан күбрәк баланы үз эченә алган өч яисә аннан күбрәк кешедән гыйбарәт яшь гаилә өчен (йә бер яшь әти яки әнидән һәм ике яисә аннан күбрәк баладан гыйбарәт яшь гаилә өчен) бер кешегә 18 квадрат метр булган гомуми мәйданы зурлыгыннан исәпләп чыгарылган торак урын бәясенең 60 процентыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 05 июль
№ 49-ТРЗ